# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Минзәлә районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 105-ТРЗ

"Татарстан Республикасы
Минзәлә районы буенча
Татарстан Республикасы
җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

## Татарстан Республикасы Минзәлә районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы

### 1 нче суд участогы

1 нче суд участогы чигенә "Минзәлә шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге, Минзәлә шәһәренең төньяк өлешендә Татарстан урамы белән Төньяк урамы кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып зират территориясен урап ала, яңадан Төньяк урамына әйләнеп кайта, Кызыл Армия урамы белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба Кызыл Армия урамы буйлап көньякка таба М.Горький урамы белән кисешү ноктасына кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, М.Горький урамының күчәр сызыгы буйлап көнчыгышка таба уза, аннары Губкин урамына күчә, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, аның күчәр сызыгы буйлап Октябрь урамы белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Октябрь урамының күчәр сызыгы буйлап Кадомцевлар урамы белән кисешкәнгә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Кадомцевлар урамының күчәр сызыгы буйлап көнчыгышка таба Гурьянов урамы белән кисешкәнгә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Гурьянов урамының күчәр сызыгы буйлап Социалистик урамы белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Социалистик урамының күчәр сызыгы буйлап көнчыгышка таба канализация насос станциясе территориясе районындагы Социалистик урамындагы инешле чокыр аша салынган күпернең көнчыгыш чигенә кадәр барып җитә, аннары Түбән Кама сусаклагычы юнәлешендә чокыр буйлап көньякка таба аның яр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба әлеге ноктадан алып Минзәлә шәһәрен урап уза һәм Түбән Кама сусаклагычы яры буйлап Мәскәү – Уфа (М-7) автомобиль юлындагы Минзәлә елгасы аша салынган күпернең төньяк чигенең көнбатыш ноктасына кадәр барып җитә, алга таба Минзәлә елгасы аша салынган күпернең көнбатыш ноктасыннан алып Мәскәү – Уфа (М-7) автомобиль юлының көнбатыш чиге буйлап төньяк юнәлештә "Пугачевский вал" кемпингы бинасының көнбатыш чигенә кадәр бара, алга таба кемпинг бинасыннан алып кемпинг территориясенең көнбатыш чиге буйлап аэроклубның очу

полосасының төньяк-көнбатыш ноктасына кадәр уза, аннары әлеге ноктадан алып аэроклубның очу полосасының төньяк чиге һәм аэроклуб территориясенең төньяк чиге буйлап, аннары аның көнчыгыш чиге буйлап төньяк әйләнгеч юл белән кисешү ноктасына кадәр бара, аннары төньяк әйләнгеч юл буйлап төньяк-көнчыгышка таба Минзәлә урман хуҗалыгына кадәр уза, аннары Минзәлә урман хуҗалыгын урап ала һәм Төньяк урамына килеп чыга, аның буйлап Татарстан урамы белән кисешү ноктасына кадәр бара.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле, Аю, Бикбау, Воровский исемендәге, Иркәнәш, Николаевка, Яңа Мажын, Яңа Мәлкән һәм Иске Матвеевка авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә "Минзәлә шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Төньяк урамының Кызыл Армия урамы белән кисешкән җирдә урнашкан тоташу ноктасыннан алып Төньяк урамыннан башлангыч алган М.Горький, М.Җәлил, Гермак, Апалы-сеңелле Есиналар, Октябрь, Сәлимов, Костин урамнарын көнбатыш, төньяк һәм көнчыгыш яклардан урап ала, аннары Төньяк урамына кире кайта һәм Төньяк урамы буйлап 317 нче Минзәлә автоягулык салу станциясенә кадәр барып җитә, аның территориясен көнбатыш һәм төньяк яклардан урап ала, алга таба көнчыгыш юнәлештә су алу җайланмасы ягына таба китә торган автомобиль юлының көнбатыш чиге белән кисешкәнгә кадәр уза, аннары, "Минзәлә өлкәннәр һәм инвалидлар интернат йорты" дәүләт бюджет учреждениесен һәм "Минзәлә машина-технология станциясе" ҖЧҖен көнбатыш һәм төньяк якларыннан әйләнеп, төньякка таба борыла, алга таба "Минзәлә машина-технология станциясе" ҖЧҖеннән килүче юл буйлап грунт юлга таба борылышка кадәр барып җитә, аннары грунт юл буйлап элеваторга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә уза, элеватор территориясенә кадәр барып җитә, шуннан соң грунт юл буйлап көнчыгышка таба борыла һәм чистарту җайланмалары территориясенә кадәр барып җитә, чистарту җайланмалары территориясен төньяк һәм көнчыгыш якларыннан урап уза һәм көньяк юнәлештә Түбән Кама сусаклагычының яр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр төшә, Түбән Кама сусаклагычының яр сызыгы буйлап 1 нче суд участогы көньяк чигенең көнчыгыш ноктасына кадәр уза, аннары Түбән Кама сусаклагычының яр кисешү ноктасыннан алып канализация насос станциясе территориясе янында урнашкан Социалистик урамындагы инешле чокыр аша салынган күпернең көнчыгыш чигенә кадәр бара, алга таба күпернең көнчыгыш чигеннән алып, так якта урнашкан йортларны кертеп, Социалистик урамы буйлап көнбатыш юнәлештә Гурьянов урамы белән кисешкәнгә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Гурьянов урамының күчәр сызыгы буйлап Кадомцевлар урамы белән кисешкәнгә кадәр бара, так якта урнашкан йортларны кертеп, Кадомцевлар урамының күчәр сызыгы буйлап Октябрь урамы белән кисешкәнгә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Октябрь урамының күчәр сызыгы буйлап Губкин урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба,

так якта урнашкан йортларны кертеп, Губкин урамының күчәр сызыгы буйлап М.Җәлил урамы белән кисешкәнгә кадәр уза, аннары Губкин урамының М.Җәлил урамы белән кисешкән җирдән алып М.Горький урамының төньяк өлеше буйлап көнбатыш юнәлештә Кызыл Армия урамы белән кисешкәнгә кадәр бара, алга таба Кызыл Армия урамының М.Горький урамы белән кисешкән җиреннән алып, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Кызыл Армия урамының күчәр сызыгы буйлап төньяк юнәлештә Төньяк урамы белән кисешкәнгә кадәр бара.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Минзәлә муниципаль районының Югары Тәкермән, Кадрәк, Коноваловка, Хуҗамәт, Наратлы Кичү, Тауасты Байлар, Иске Мажын, Ырыс, Юртово һәм Юшады авыл җирлекләре.